ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 сентябрь 2021 ел № 5765

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алу хокукына конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 14 апрелендәге 1828 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алу хокукына конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 14 апрелендәге 1828 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2020 елның 4 сентябрендәге 4387 номерлы, 2021 елның 23 апрелендәге 2861 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта:

- 2 пунктчада «2 нче кушымта» сүзләрен «3 нче кушымта» сүзләренә алмаштырырга;

- түбәндәге эчтәлектәге 3 пунктча өстәргә:

«3) 2 нче кушымтада каралганча, ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү турында шартнамә»;

2) 1 нче кушымтада:

- 2 пунктта «24 августтан 31 августка кадәр» сүзләрен «15 сентябрьдән 30 сентябрьгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

- 18 пунктта:

беренче абзацта «24 августка кадәр» сүзләрен «15 сентябрьгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктчада «(булганда)» сүзен төшереп калдырырга;

- 19 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктчаны өстәргә:

«4) башлангыч аккредитация нәтиҗәләре буенча баллар»;

- 21 пунктта «10 (ун)» сүзен «7 (җиде)» сүзенә алмаштырырга;

- 25 пунктта «80 (сиксән) мең сум» сүзләрен «100 (йөз) мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2 нче кушымтаның 1.3 пунктындагы «80 (сиксән) мең сум» сүзләрен «100 (йөз) мең сум» сүзләренә алмаштырырга»;

4) 3 нче кушымтада:

- Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алуга конкурс үткәрү буенча комиссия составыннан Л.Ә. Камалетдинованы төшереп калдырырга;

- Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алуга конкурс үткәрү буенча комиссия составына комиссия әгъзасы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе урынбасары, дәвалау һәм халыкка профилактика ярдәме бүлеге башлыгы Ногманов Рөстәм Марат улын кертергә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов